Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары__________ З.К. Габдрахманова

Сауш төп гомумбелем бирү мәктәбе директоры__________ И.Х.Нигематзянов

# "Яшьлек" укучылар үзидарәсе программасы.

Теләче муниципаль районы
Сауш төп гомумбелем бирү мәктәбе
педагог-оештыручы: Габдрахманова З.К.

**Аңлатма язуы**

Балалар оешмасы - иҗтимагый тормыш мәктәбе ул. Анда катнашу, буш вакытны файдалы һәм кызыклы итеп үткәрергә, шәхес буларак танылырга ярдәм итә. Үз оешмаларында балалар кирәкле фикерне тыңлый белергә, активлык күрсәтергә, уңай традицчяләрне сакларга һәм яңаларын барлыкка китерергә өйрәнәләр.

2017-2018 нче уку елында Теләче районы Сауш төп омумбелем бирү мәктәбендә барлыгы 28 бала исәпләнә.

ЭЗТАБАРлар - 7 ( 2 эзтабарлар группасы, 1- 3 һәм 2-4 нче сыйныфлар);

ВАРИСлар - 19 ( 5 варислар группа, 5-6-7-8 -9 нчы сыйныфлар);

"Яшьлек" оешмасы – 26 ( 2-9 нчы сыйныфлар).

Барлык класстан тыш чаралар «Яшьлек" оешмасының эшчәнлеге булып тора. Бу оешма 2-9 класс укучыларын үз эченә ала. Оешма тулысы белән укучылар үзидарәсенә корылган. Аның югары органы булып мәктәпкүләм укучылар җыелышы санала. Анда күптөрле мәктәп тормышына кагылышлы мәсьәләләр карала. Мондый типтагы структурада эшләү укучылар өчен кызыклы, мавыктыргыч. Алар үзләрен мәктәпнең чын хуҗалары итеп тоялар. Оешманы оештыруның максаты да шуңа нигезләнә: шәхесне һәр яклап үстерүгә булышлык итү, яшь буынны мөстәкыйль тормышка әзерләү, татар халкының бай рухи мирасы нигезендә, гармонияле актив эш итүче, иҗади шәхес формалаштыруга омтылу.

Үз оешмаларында балалар башка кешеләрне тыңлый белергә, уңай традицияләрне сакларга һәм яңаларын барлыкка китерергә өйрәнәләр. Оешмада башкарыла торган эшләр мөстәкыйльлеккә, ирекле аралашуга, үзенә ошаган эшне сайлап ала белергә, сәләтеңне үстерергә өйрәтә.

- Балалар оешмалары-иҗтимагый хәрәкәтләрнең бер өлеше. Алар яшь буынны тормышка әзерләүдә, аның хокукларын яклауда зур әһәмияткә ия.

**Оешманың төп максаты:**

- балалар һәм яшь үсмерләрнең иҗади сәләтен ачу һәм үстерү;
- балаларда Татарстанның киләчәген тәэмин итүдә үзләреннән өлеш кертүче яшүсмерләр тәрбияләү;

- алда үзләре, башка кешеләр, киләчәк буыннар алдында җаваплылык хисе тәрбияләү, оешманың һәр әгъзасының тормышын кызыклы итеп оештыру, янәшәбездә яшәүче милләтләрнең гореф - гадәтләрен ихтирам итүгә ирешү.

**Бурыч:**

- Баланың мөстәкыйльлегенә игътибар итү
- Конкурс һәм ярышларда катнашу
- Укуга аңлы караш булдыру өчен белем белән бәйле кичәләр, бәйгеләр үткәрү
- Спорт - сәламәтләндерү өлкәсендә күңелле стартлар, спорт уеннары оештыру
- Кызыклы уеннар, очрашулар оештыру,бу эшкә сәләтле балаларны тарту
- Өлкәннәргә ихтирам хисе тәрбияләү,! имурчылык хәрәкәтен пропагандалау
- Тәрбия чараларын үткәргәндә бәйрәм буласы залны милли рухта бизәүгә игътибар итү
- Укучыларда милли үзаң формалаштыру

Укучылар үзидарәсе баланы мөстәкыйльлеккә, кешеләр белән аралашырга, карар кабул итәргә һәм кылган гамәлләре өчен җавап бирергә өйрәтә. Үзидарә үсеше өчен мәктәп тормышында һәр сыйныфның һәм һәр баланың да теләп катнашуы һәм бердәм юнәлешгә үзәкләшкән җитәкчелек буенча эшләве мөһим.

Гомумән алганда, балалык еллары - кеше тормышында шәхес буларак үсеш чоры. Балачакта һәркем файдалы эшчәнлектә катнашырга, яшьтәшләре белән аралашырга, коллективта үзен күрсәтергә, танылырга омтыла һәм бу шулай булырга тиеш тә. Шуңа күрә бу чорда малайлар һәм кызлар төрле оешмаларга, төркемнәргә берләшүе бик табигый хәл.

Укучылар оешмаларда вакытны файдалы һәм кызыклы итеп үткәрергә өйрәнә, интелектуаль, экологик, мәдәни, хезмәт, спорт - сәламәтләндерү, уен һәм башка төр эшчәнлектә катнаша.

Чыннан да, балалар оешмасы ул - һәркемгә һәртөрле эшне эшли алырга ярдәм итә торган оешма. Мәктәпләрдә укучылар оешмасының эше нәкъ менә шундый итеп оештырылган.

Безнең мәктәптә дә "Яшьлек" укучылар оешмасы эшләп килә. Оешмада үзидәрәсе председателе эшли. Оешма эшчәнлегенә, утырышларның һәм укучыларның гомуми җыелышларның үгүе өчен оешманың җитәкчесе булган

председателе җавап бирә. Ә инде төрле юнәлештәге эшчәнлегенә аерым активлар билгеләнгән. Оешмада укучылар звеноларга бүленгән. Кагыйдәләрен, законнарын өйрәнәләр.

**Укучылар үзидарәсенең гомуми положениесе**

1. Укучылар үзидарәсе советы, мәктәптә тупланган коллективны төзүдә актив катнашучы укучыларда җаваплылыкны арттыра һәм үзанын үстерүдә зур өлеш кертә.
2. Коллектив советы уку елы башыннан 2 елга ябык тавыш бирү юлы белән сайлана.
3. Коллектив советына 9-11 класслардан дисциплиналы, аеруча актив, иптәшләрен үз артыннан ияртә ала торган , авторитетлы укучылар сайлана;
4. Коллектив советына ничә укучы сайлануын гомуми җыелышларда ачыклана.

**Үзидарә эшенен бурычлары һәм эчтәлеге**

Укучылар үзидарәсе, дәрестән тыш хезмәт тәрбиясе, үз -үзенә хезмәт күрсәтү, җәмгыять милкенә карага сакчыл караш тәрбияләүне, аңлы дисциплинаны тәрбияләүне һәм укучыларның әдәплелеген, мәктәпнен эчке кагыйдәләрен үтәүне булдыра.

Укучылар үзидарәсе оешмасы укуда, белем алуда, конкурслар, кичәләр үткәргәндә узара ярдәм күрсәтүне оештыра

Укучылар үзидарәсе оешмасы хезмәтне оештыруда, аларның эшчәнлегенә зур ярдәм күрсәтә

Укучылар үзидарәсе мәктәптә үз - үзенә хезмәт күрсәтүне оештыра; классларны җыештыруны, мәктәп территориясендә уңайлы шартлар тудыруны, класслардагы җиһазларны саклауны оештыра

Үзпдарә эшен оештыру

1. Оешмага сайланган укучылар арасыннан үзидәрә председателе, анын активлары сайлана.
2. Мәктәпнең укыту - тәрбия эшчәнлегенә нигезләнеп укучылар үзидарәсе комиссия төзи:

- уку буенча
- хезмәт буенча

- сәнгать буенча
- спорт буенча
- шефлык буенча.

«Яшьлек» укучылар оешмасы эшне түбәндәге юнәлешләрдә алып бара:

* Уку юнәлелеше
* Культура - агарту
* Спорт
* Танып-белү
* Хезмәт тәрбиясе һәм тимурчылык эше

- сәнгать буенча
- спорт буенча
- шефлык буенча.

«Яшьлек» укучылар оешмасы эшне түбәндәге юнәлешләрдә алып бара:

* Уку юнәлелеше
* Культура - агарту
* Спорт
* Танып-белү
* Хезмәт тәрбиясе һәм тимурчылык эше

**«Яшьлек» укучылар үзидарәсенең составы үзидарә председателе һәм активлардан тора, аларнын үз вазыйфалары бар**

| | |
|---|---|
| Үзидарә председателе | - оешма активлары белән тиешле югарылыкта идарә итә<br>- һәр активның үз эшен тиешле югарылыкта һәм төгәл башкаруын таләп итә<br>- Кирәк очракта активларга гомуми җыелышларда чыгыш ясарга тәкъдим итә.<br>- һәр утырышлар һәм җыелышларның беркетмәсен яза |
| Уку активының җаваплылыгы | - Класстагы уку секторлары белән даими эшли<br>- Фәннәрне авыр үзләштерүче укучылар белән класстагы уку секторларының эшләвен таләп итә<br>- Атна саен класстагы билгеләр белән линейкада тапыштыра., начар билгеләр алган очракта аны төзәтү өстендә эш алып бара |
| Сәнгать активының җаваплылыгы | - «Укучылар иҗаты» стендын системалы рәвештә үзгәртеп тора<br>- Мәктәп буенча үткәрелә торган кул эшләре конкурслары үткәрүне булдыра<br>- Бәйрәмнәрдә залларны бизәүне классларга чиратлап бүлеп бирә<br>- Бәйрәм өчен бүләкләр әзерләгәндә булышлык итә<br>- Классларлагы сәнгать секторларының эшенә җитәкчелек итә һәм эшләрен төгәл башкаруларын таләп итә<br>- Озын тәнәфесләрдә күңелле уеннар оештыра<br>- Бәйрәмнәрне, кичәләрне алып баруда ярдәм итә |
| тимурчылык | - Билгеләнгән классларның һәйкәлне чистартып торуларын таләп итә<br>- Классларлагы тимурчылык эшенә җитәкчелек итә<br>- Мәктәп буенча үткәреләчәк Бөек Җиңү бәйрәменә |

| | |
|---|---|
| | багышланган чараларны алып бара<br>- Хәрби - патриотик рухта үткәрелә торган «Аҗаган» уенын оештыруда булышлык итә<br>- Хәзерге вакытта исән булган сугыш ветераннарының , тыл ветераннарының исемлеген булдыра<br>- Ветераннар белән, сугыш чоры балалары белән классларда очрашулар үткәрүне таләп итә |
| Спорт һәм туризм | - һәр атнада җомга көнне иртәнге гимнастиканы оештыра<br>- Класслардагы спорт секторлары белән берлеккә мәктәп күләмендә үгкәреләчәк спорт ярышларында башлап йөри<br>- Ярышларның нәтиҗәләре белән линейкада таныштыра<br>- Шахмат, шашка ярышлары үткәрүдә житәкчелек итә |
| Тәртип саклау өчен җаваплы кеше | - Мәктәптәге эчке тәртип кагыйдәләрен һәм укучылар өчен кагыйдәләрне тирәнтен өйрәнә<br>- Классларда министрлар белән берлектә укучыларның киемнәре, чисталыклары буенча рейдлар үткәрә<br>- Класслардагы мебельләрнең сакланышына күзәтчелек итә<br>- Мәктәп эчендә, дискотекаларда тәртип булуын таләп итә |

**Безнең мәктәптә үзидарәнең төзелеше ике дәрәҗәдә**

| | |
|---|---|
| Беренче дәрәҗә | Классларда укучылар үзидарәсе<br>Классларда укучылар җыелышы<br>Класс советлары<br>Класс үзидарәсенең эш бүленеше |
| Икенче дәрәҗә | Мәктәптә укучылар үзидарәсе "Яшьлек" укучылар |

| | |
|---|---|
| | оешмасының гомуми җыелышы |
| | активлар утырышы (класс старосталары белән берлектә) |

**Укучылар үзидарәсенең төп функцияләре:**

Гомуми җыелыш

- Еллык эш планнарын карый һәм раслый
- Укучылар оешмасы белән бәйләнешле сорауларны чишә
- һәр класс һәм һәр җаваплы активның эшчәнлеге отчетларын тыңлый һәм фикерләрен бәяли
- Укучыларның коллектив эчендәге эшчәнлеген чагылдыручы инструкцияләрне карый һәм раслый

**Активлар утырышы:**

- Мәктәптән тыш һәм класстан тыш эшләрне планлаштыра һәм оештыра
- Укучыларның үз - үзенә хезмәт күрсәтүләрен оештыра, дежурлыкка һәм мәктәптә тәртипне саклауга ярдәм итә
- Кечкенә классларга зур классларны ярдәмгә билгели
- Укучыларның җыелышын әзерли һәм үткәрә
- Үткәреләсе мероприятиеләр турында фикер алыша, үткәрү планын раслый

**Укучылар өчен кагыйдәләр**

Укучылар мәктәп Уставы таләпләрен үтәргә, тырышып укырга, мәктәп милкенә сак карарга, укытучылар һәм хезмәткәрләрне, иптәшләрен хөрмәт итәргә, аларның

хезмәтенә намус белән карарга, мәктәпнең эчке тәртип кагыйдәләрен үтәргә бурычлы:

- дәресләр, түгәрәкләр расписаниесен төгәл үтәргә, дәресләргә вакытында керергә, сәбәпсез дәресләр калдырмаска;
- мәктәптә һәм мәктәп территориясендә чисталыкны сакларга;
- электр энергиясен саклык белән тотарга;
- укытучы һәм хезмәткәрләргә хөрмәт белән карарга, һәрвакыт аларга ярдәм итәргә;
- дежурлык вазыйфасын тиешенчә үтәргә, мәктәп, классны даими чиста тотарга;
- ашханәдә, чишенү бүлмәсендә, бәдрәфтә чисталык һәм тәртип булдырырга;
- мәктәпне яңа уку елына әзерләүдә ярдәм итәргә (5 - 9 класс);
- үз сәламәтлегең һәм башкаларның сәламәтлегенә игътибарлы булырга;
- мәктәп һәм класс үзидарәсе законнарын төгәл сакларга;
- мәктәптә уку формасыннан, кызларга ак альяпкычлардан йөрергә, малайларга ак күлмәктән, костюм-чалбарлардан, галстуктан йөрергә, барлык укучыларга да икенче аяк киеме булдырырга;
- кызларга чәчләрен үреп, ак бантиктан, егетләргә чәчләрен кыскартып, чиста-пөхтә йөртергә;

**Укучыларга катгый рәвештә тыела:**

- мәктәпкә кесә телефоннары, дәрескә кирәкмәгән әйберләр алып килү;
- джинсы киемнәр киеп йөрү;
- мәктәп территориясендә көнбагыш ашау, чүпләү;
- бер - берең белән ачуланышу, физик көч куллану, бер - берең белән тупас итеп аңлашу
- иптәшләреңә һәм мәктәп хезмәткәрләренә тупас мөнәсәбәттә булу;

## Мәктәп укучылары өчен бердәм таләпләр

1. Белем нигезләрен үзләштер, үз белемеңне күтәрү өстендә тырышып һәм иҗади эшлә. Алган белемеңне тормышта файдалану.
2. Үзеңне кызыксындырган, үзеңә ошаган һөнәр сайларга омтыл. Хезмәт дисциплинасын сакла, куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен төгәл үтә.
3. Класс, мәктәп җәмгать тормышында актив катнаш.
4. Мәктәп һәм коллективның традицияләрен сакла һәм үстер.Түбән класс укучылары белән класстан тыш эшне оештыруда укытучыларга һәм укучыларга ярдәм ит.
5. Укытучы һәм иптәшләрең фикерен бүлдермичә тыңларга өйрән.
6. Кыз балаларга игътибарлы бул, аларны хөрмәт ит.
7. Уку, хезмәт һәм ялыңны дөрес оештыр, вакытыннан дөрес файдалан. Мәдәни һәм рухи хәзинәлөребездән дөрес файдалан . Үзеңнен сәлатеңне үстер.

8. Физкультура һәм спорт белән даими шөгыльлән, үзеңне чыныктыр. Үзеңнең сәләтеңә туры килүче түгәрәк яки секциягә йөр.
9. Эти - әни, туганнарыңны хөрмәт ит, аларга булыш. Авыру, өлкән, кечкенә кешеләр турында кайгырт.
10. Тәртипле, тыйнак, игътибарлы бул. Зарарлы гадәтләргә, җәмгыятькә каршы күренешләргә түзеп торма, тәртип саклауда катнаш.
11. Үзеңнең тышкы кыяфәң турында кайгырт: гади һәм пөхтә итеп киенә бел. Кеше арсында үзеңне тыйнак тот.
12. Юл йөрү кагыйдәләрен бел. Беренче медицина ярдәме күрсәтергә өйрән.

**Сауш төп мәктәбе укучылары өчен кагыйдәләр:**

1. Укучы чиста, пөхтә киенеп дәресләр башланырга 30 мин. кала килә, чишенеп класска кергәч, үзенең эш урынында алдагы дәрескә кирәкле әсбапларны әзерли.
2. Мәктәпкә төрле куркыныч әйберләр, агулы матдәләр алып килергә ярамый.
3. Укытучы яки башка өлкән кеше класска кергәндә укучылар басып каршы ала.
4. Дәрес вакытында укытучы, класс җитәкчесе рөхсәтеннән башка мәктәптән китәргә ярамый.
5. Укучы олыларга, кызларга карата хөрмәт, кечкенәләргә карата кайгыртучанлык күрсәтә.
6. Тәнәфестә эш урынын тәртипкә китерә, классны тәртипли, калган вакытта каридорда була.
7. Тәнәфестә коридорда йөгерү һәм башкаларга ял итәргә комачаулау тыела.
8. Дежур укучы 7.30 мин.та килә, тәнәфестә класста була, тәртип өчен җавап бирә, дәрескә килмәүчене ачыклый.
9. Мәктәп буенча дежур укучы 7.30 мин.та килә, үз посты өчен җавап бирә.
10. Укучылар мәктәп ашханәсенә билгеләнгән вакытка баралар һәм андагы кагыйдәләргә буйсыналар.
11. Укучылар мәктәп милкен саклап тоталар, үзләренең һәм иптәшләренең милкенә сак караштa булалар
12. Мәктәптән читтә укучылар үз намусларына һәм үз мәктәбе исеменә тап төшмәслек итеп тоталар.

**Көтелгән нәтиҗә**

Чыннан да, балалар оешмасы ул - һәркемгә һәр төрле эшне эшли алырга ярдәм итә. Безнең «Яшьлек» исемендәге укучылар үзидарәсе эше нәкъ менә шуның өчен оештырылган.

учылар оешмасында балалар вакытны файдалы һәм кызыклы итеп үткәрергә нә. Мөстәкыйльлеккә, үз эшенә җаваплы карауга омтыла, кешеләр белән н мөгамәләдә эш итәргә кирәклеген аңлый.

идарәдәге эшләрнең төрле юнәлештә һәм күп төрле булуы укучыларның төрле сәләтен ача. Ә инде аларга шәхси баллар кую , баланың һәрьяклы үсешенә йогынты ясый. Бала үз-үзен үстерү өстендә ныграк эшли башлый. Чөнки ракта һәркемнең алдынгы буласы килә. Димәк, оешма эше укучыларның укуда лемнәрен ныгыта, төрле конкурс, ярышларда катнашуга мөмкинлекләр ра.

идарәдә тәрбияләнгән укучылар – тормышта үз юлләрын дөрес табарга, үз ә җаваплылык алган очракта тиешле югарылык ала, җиренә җиткереп ргә өйрәнә. Кешеләр белән аралашучанлык, үзенең фикерен башкаларга ерә белүчәнлек сыйфатларына ия була.

чылар оешмасында балалар вакытны файдалы һәм кызыклы итеп үткәрергә ә. Мөстәкыйльлеккә, үз эшенә җаваплы карауга омтыла, кешеләр белән мөгамәләдә эш итәргә кирәклеген аңлый.

дарәдәге эшләрнең төрле юнәлештә һәм күп төрле булуы укучыларның төрле сәләтен ача. Ә инде аларга шәхси баллар кую , баланың һәрьяклы үсешенә йогынты ясый. Бала үз-үзен үстерү өстендә ныграк эшли башлый. Чөнки акта һәркемнең алдынгы буласы килә. Димәк, оешма эше укучыларның укуда емнәрен ныгыта, төрле конкурс, ярышларда катнашуга мөмкинлекләр е.

идарәдә тәрбияләнгән укучылар – тормышта үз юлләрын дөрес табарга, үз е җаваплылык алган очракта тиешле югарылык ала, җиренә җиткереп гә өйрәнә. Кешеләр белән аралашучанлык, үзенең фикерен башкаларга рә белүчәнлек сыйфатларына ия була.

се

ь районы
ү мәктәбе
анова З.К.

Прошито, пронумеровано и скреплено печатью

(11) одиннадцать листов

Директор школы: ________ Нигематзянов И.Х.